ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 19 » 09 2025 ел Мөслим № 437

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2028 елларга Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексны программаны раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 609 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182 номерлы Федераль закон нигезендә хокук бозуларны профилактикалауның, хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын ныгытуның күпдәрәҗәле системасын булдыру, күрсәтелгән эшчәнлеккә дәүләт органнарын, иҗтимагый оешмаларны һәм халыкны җәлеп итү, җинаятьләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны локальләштерү, шулай ук «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, **КАРАР БИРӘМ:**

1. «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексны программаны раслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 22 декабрендәге 609 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 Кушымта нигезендә 2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплексны программага «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлек һәм хокук бозуларны профилактикалау» ярдәмче программасы өстәргә.

1 Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (https://pravo.tatarstan.ru/).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе И.Ф. Салихҗанов**